| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.03.2025 № 343

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 ноябрендәге 1112 номерлы карары белән расланган «2015 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 17 гыйнварындагы 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенең 5 бүлегендәге 4-8 пунктлары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 ноябрендәге 1112 номерлы карары (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 сентябрендәге 819 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 493 номерлы, 2021 елның 30 июнендәге 629 номерлы, 2021 елның 14 сентябрендәге 940 номерлы, 2021 елның 24 сентябрендәге 1012 номерлы, 2022 елның 25 июлендәге 799 номерлы, 2024 елның 26 гыйнварындагы 81 номерлы, 2024 елның 17 июлендәге 778 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган «2015 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Муниципаль программа паспортын һәм программага кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин